**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Бигеш авыл җирлегенең Югары Лоҗы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**14 ноябрь 2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 14 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Югары Лоҗы торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:
- зират өчен җиһазлар (чүп чүкеч һәм электр генераторы) сатып алу;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәленең мемориаль тактасын алыштыру;
- яктырткычлар алыштыру».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 89 кеше кертелгән, җыенында 49 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе буенча гражданнар җыенында катнашучыларның 44 кеше тавыш бирде;

“Каршы” дип 5 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Югары Лоҗы торак пунктында гражданнар җыены үткән, гражданнар җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Югары Лоҗы торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:
- зират өчен җиһазлар (чүп чүкеч һәм электр генераторы) сатып алу;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәленең мемориаль тактасын алыштыру;
- яктырткычлар алыштыру» - дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зәй муниципаль районы
Бигеш авыл җирлеге башлыгы** **И.Р.Вәлиев**